# КАРАР (РЕШЕНИЕ)

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге составына керүче Югары Симет торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

01.11.2024 № 2

2003 елның 6 октябрендәге № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары , 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсе, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге Советының 17.12.2021 елның 26 номерлы «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау турында» карарына таянып 2024 елның 01 ноябрендә узган гражданнар җыенында «2025 нче елда Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге составына керүче Югары Симет торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде һәм җыелган акчаларны конкрет тоту юнәлешенә җибәрү турында:

-Ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Югары Симет торак пунктында традицион күмү урыннарын киртәләү)

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган, гражданнар җыенына 263 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 134 кеше тавыш бирүдә катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
«Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашкан 134 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1.Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге составына керүче Югары Симет торак пунктында халык җыенын үткән дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре – чын мәгънәсендә дип танырга.

2. «2025 нче елда Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге составына керүче Югары Симет торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешәсезме?» дигән мәсьәлә буенча карар кабул итәргә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге киләсе мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә:

-Ремонт, коймалар кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Югары Симет торак пунктында традицион күмү урыннарын киртәләү)

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлегенең

рәсми сайтында http://saby.tatarstan.ru/simet адресы буенча һәм авыл җирлегендә урнашкан информацион стендларда урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Югары Симет авыл җирлеге башлыгына, Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче,
Югары Симет авыл
җирлеге башлыгы И.Р.Әхмәдуллин